| | |
|---|---|
| МАМАДЫШ-АКИЛОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 31 октябрь** Мамадыш-Әкил ав. **№ 18**

Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтерлык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (2019 елның 22 август 11 номерлы, 2020 елның 30 сентябрь 16 номерлы, 2021 елның 09 мартындагы 11 номерлы, 2024 елның 17 июнендәге 11 номерлы карары белән) үзгәрешләр кертү турында

Бухгалтерлык хезмәте хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ::

1 Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерлык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктына (Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган (2019 елның 22 август 11 номерлы, 2020 елның 30 сентябрь 16 номерлы, 2021 елның 09 мартындагы 11 номерлы, 2024 елның 17 июнендәге 11 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Баш бухгалтерның вазыйфаи окладына түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектә халык саны | Вазыйфаның исеме, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш бухгалтер | Бухгалтер |

| | | |
|---|---|---|
| 3,5 мең кешегә кадәр | 25 700 | |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин ур., 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы); Татар Танае авылы, Үзәк урамы, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы); Паново авылы, Үзәк бина, 26в йорт (авыл клубы) урнаштырырга.

Мамадыш-Әкил авыл Җирлек башлыгы,
Совет рәисе: Ф.Ф.Мирхәтуллин